СОВЕТ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

от 23.09.2021г. п.г.т. Аксубаево № 80

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Трудолюбово авыл җирлегенең генераль планын раслау турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Трудолюбово авыл җирлегенең тотрыклы үсеше өчен шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003, №131-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына таянып, ачык тыңлаулар беркетмәсен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан килештерелгән генераль план проекты буенча 26.11.2018, №10-53/15696 бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Трудолюбово авыл җирлегенең генераль планын кушымталар нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе К.К.Гыйлманов